СОВЕТ НИЖНЕТАКАНЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Банковская, д.17, с. Нижний Таканыш, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422140

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ТӘКӘНЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Банк ур., 17 нче йорт, Түбән Тәкәнеш авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422140

тел.(факс): (85563) 2-63-21; e-mail: Nakt.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар — Решение

«19» февраль 2020 ел — № 5-50

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 20 нче декабрендә кабул ителгән 3-36 нче номерлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен раслау турындагы» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында»

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 02 августындагы 283-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 августындагы 342-ФЗ номерлы Федераль закон,«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 августындагы 340-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 20 нче декабрендә кабул ителгән 3-36 нче номерлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен раслау турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 12 статьяның 4 пунктында «ун көн» сүзләрен «җиде эш көне» сүзләренә алмаштырырга»;
1.2. 22 статьяның 7 пунктындагы 4 абзацында «ундүрт көн» сүзләрен «җиде эш көне» сүзләренә алмаштырырга»;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында,Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru).урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /Хәмизуллин Р.Ж./